| ГЛАВА<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2023 г.Бавлы № 170

Баулы муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 30 июнендәге 62 номерлы «Баулы муниципаль районы Советы Аппаратында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы

К А Р А Р И Т Ә М:

1. Баулы муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 30 июнендәге 62 номерлы «Баулы муниципаль районы Советы Аппаратында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Баулы муниципаль районы Советы Аппаратында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш тәртибендә:

2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның мөрәҗәгате (алга таба-мөрәҗәгать) – язма рәвештә җирле үзидарә органына яисә вазифаи затка җибәрелгән яки электрон документ

формасында, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр)» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданинның җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»;

5.1 пунктында «язма мөрәҗәгатьтә», «язма мөрәҗәгатьне җибәрә» сүзләрен «язма формада мөрәҗәгатьләр», «мөрәҗәгатьне язма формада җибәрә»сүзләре белән алмаштырырга;

5.2 пунктында «язма мөрәҗәгатькә» сүзләрен «язма формада» сүзләре белән алмаштырырга, түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Мөрәҗәгатьтә гражданин мәҗбүри тәртиптә үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта) күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын яки Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификатор) файдалана, аның буенча җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш. Гражданин әлеге мөрәҗәгатькә электрон формада тиешле документларны һәм материалларны кушарга хокуклы.»;

6.5 пунктында «электрон документ формасында» сүзләреннән соң «яки аны кулланганда гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинеты адресы (уникаль идентификатор) буенча» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы

И.И. Гозәеров